ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӘҖМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

КАРАР

«25» сентябрь2024 ел №13

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәйавыл җирлеге территориясендә беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге 15 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 14 апрелендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хәрби исәпкә алу турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте актларының аерым нигезләмәләре үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2023 елның 25 июлендәге 1211 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге 15 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге территориясендә беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Яшәү урыны яисә булу урыны буенча (3 айдан артык вакытка), шул исәптән теркәлү белән расланмаган яшәү урыны һәм (яисә) булу урыны буенча яки альтернатив граждан хезмәте узу урыны буенча гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашырырга. Беренчел хәрби исәпкә алу торышы өчен җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе җавап бирә.»;

1.2. 3.5 пунктында «муниципаль берәмлек (муниципаль берәмлекләр)» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре Комсомол районы һәм Тукай районы» сүзләренә алыштырырга»;

1.3. 3.7 пунктында «муниципаль берәмлекнең (муниципаль берәмлекләрнең)» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре Комсомол районы һәм Тукай районы» сүзләренә алыштырырга»;

1.4. 3.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8. 1 ноябрьгә кадәр Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре Комсомол райны Тукай районы хәрби комиссарының кәгазьдә язма формада төзелгән яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасындагы запросы буенча беренче тапкыр хәрби исәпкә куелырга тиешле гражданнар турында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 27 ноябрендәге 719

номерлы карары белән расланган хәрби исәпкә алу турында нигезләмәгә 6 кушымта нигезендә форма буенча белешмәләр бирергә.»;

1.5. 4.1 пунктында:

Өченче абзацта «җирле үзидарә органы администрациясе» сүзләрен «җирлек Башкарма комитеты» сүзләренә алыштырырга;

Бишенче абзацта «җирле үзидарә органы җитәкчесе» сүзләрен «җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе» сүзләренә алыштырырга;

1.6. 5.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. «Хәрби исәп буенча хезмәткәрне вазыйфага билгеләү, күчерү һәм вазыйфадан азат итү җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре һәм Тукай районы хәрби комиссары белән килештереп уздырыла.

Хәрби исәп буенча хезмәткәр үз эшчәнлеген башка эш белән берьюлы гамәлгә ашыра.».

2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге 15 номерлы карары белән расланган Запаста торучы гражданнарны хәрби исәпкә алу һәм броньлау хезмәткәренең вазыйфаи инструкциясенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 1 пунктта:

«в» пунктчасының икенче абзацында «муниципаль берәмлек (муниципаль берәмлекләр)» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре Комсомол районы һәм Тукай районы (алга таба – хәрби комиссариат)» сүзләренә алыштырырга;

«д» пунктчасында «муниципаль берәмлек (муниципаль берәмлекләр)» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.2. 4 пунктка «, шул исәптән электрон формада» сүзләрен өстәргә;

2.3. 5 пуктта «муниципаль берәмлек (муниципаль берәмлекләр)» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.4. 6 пунктта:

беренче абзацта «муниципаль берәмлек (муниципаль берәмлекләр)» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «җирле үзидарә органы администрациясе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты (алга таба – җирлек Башкарма комитеты)» сүзләренә алыштырырга;

дүртенче абзацта «муниципаль берәмлек (муниципаль берәмлекләр)» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.5. 7 пунктта:

беренче абзацта «муниципаль берәмлек (муниципаль берәмлекләр)» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «җирле үзидарә органы администрациясе» сүзләрен «җирлек Башкарма комитеты» сүзләренә алыштырырга»;

2.6. 10 пунктта:

«муниципаль берәмлек» сүзләрен «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге (алга таба – җирлек)» сүзләренә алыштырырга;

«муниципаль берәмлекләрнең хәрби комиссарлары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре Комсомол районы һәм Тукай районы хәрби комиссары (алга таба – хәрби комиссар)» сүзләренә алыштырырга;

икенче җөмләдә «хәбәр итәләр» сүзләре алдыннан «, шул исәптән электрон формада» сүзләрен өстәргә;

өченче җөмләдә «аларга хәбәр итәләр» сүзләре алдыннан «, шул исәптән электрон формада» сүзләрен өстәргә;

2.7. 11 пунктта:

беренче абзацта «муниципаль берәмлек (муниципаль берәмлекләр)» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «җирле үзидарә органы администрациясе» сүзләрен «җирлек Башкарма комитеты» сүзләренә алыштырырга;

2.8. 12 пунктта:

«муниципаль берәмлек (муниципаль берәмлекләр)» сүзләрен төшереп калдырырга;

«муниципаль берәмлек, авыл (шәһәр) җирлеге, шәһәр округы, федераль әһәмияттәге яки башка муниципаль берәмлекнең шәһәр эчендәге территорияләре» сүзләрен «җирлек» сүзенә алыштырырга»;

2.9. 13 пунктта «муниципаль берәмлек» сүзләрен «җирлек» сүзенә алыштырырга;

2.10. 15 пунктта:

«муниципаль берәмлек (муниципаль берәмлекләр)» сүзләрен төшереп калдырырга;

«Җирле үзидарә органы Башлыгы» сүзләрен «Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе» сүзләренә алыштырырга;

2.11. 17 пунктта «муниципаль берәмлекләрнең тиешле хәрби комиссариатлары» сүзләрен «хәрби комиссариат» сүзләренә алыштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Бакшарма комитет Җитәкчесе Г.Т.Хөсәинова